СОВЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** с.Старое Дрожжаное **КАРАР**

2022 елның 8 сентябре № 21/3

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 2020 елның 3 июнендәге 45/15 номерлы карары (2020 елның 12 декабрендәге 3/7 номерлы редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**түбәндәге эчтәлекле 10.1-10.3** пунктлар өстәргә:

«10.1. Комиссия рәисе түбәндәге вәкаләтләрне башкара:

1) комиссия эшчәнлегенә гомуми җитәкчелек итүне гамәлгә ашыра;

2) комиссия утырышларын уздыру урынын һәм вакытын билгели;

3) комиссия утырышларында рәислек итә;

4) утырыш беркетмәләрен, комиссия хатларын, карарларын һәм конкурс нәтиҗәләре турында хәбәрнамәләрне имзалый;

5) комиссия кабул иткән карарларның үтәлешен үз компетенциясе кысаларында контрольдә тота.

10.2. Комиссия секретаре түбәндәге вәкаләтләрне башкара:

1) комиссия утырышларын әзерләүне тәэмин итә;

2) комиссия әгъзаларына комиссия утырышын үткәрү урыны һәм вакыты турында хәбәр итә, аларны кирәкле белешмә-мәгълүмат материаллары белән тәэмин итә;

3) комиссиягә керә торган документларны һәм материалларны кабул итә, аларны рәсмиләштерүнең дөреслеген тикшерә, аларны комиссия утырышларына карау өчен әзерли;

4) комиссия утырышы беркетмәсен алып бара;

5) комиссия утырышлары, комиссия хатлары һәм карарлары беркетмәләрен рәсмиләштерә;

6) утырыш беркетмәләренә, комиссия карарларына һәм конкурс нәтиҗәләре турында хәбәрнамәләргә кул куя;

7) конкурсантларга конкурс нәтиҗәләре турында язма рәвештә хәбәр җибәрә.

10.3. Комиссиянең бүтән әгъзалары түбәндәге вәкаләтләрне башкара:

1) комиссия утырышларында, карар проектларын әзерләүдә катнашалар;

2) комиссия компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр кертәләр;

3) комиссия рәисе йөкләмәләрен үтиләр.»;

**түбәндәге эчтәлекле 22.1** пункт өстәргә:

«22.1. Конкурс сайлап алуына дәгъва кылучыларның һәрберсенең тавыш бирү нәтиҗәләре утырыш беркетмәсендә теркәлә һәм комиссия карары белән рәсмиләштерелә.

Комиссия утырышы карарына һәм беркетмәсенә аның рәисе һәм секретаре имза сала.»;

**23 пунктта** «язма рәвештә» сүзләреннән соң «йә хәбәрнамәнең скан-күчермәсе электрон почта аша җибәрелә» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыгарга тиеш.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль
районы Башлыгы, Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы Советы Рәисе: М.Р. Гафаров